ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
14.02.2024

**К А Р А Р**
№ 189

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2015-2025 елларга Биектау муниципаль районының коррупциягә каршы көрәш муниципаль программасы»н раслау турында» 2014 елның 20 октябрендәге 2004 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2025 елларга Татарстан Республикасының коррупциягә каршы көрәш сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 сентябрендәге 1150 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 20 октябрендәге 2004 номерлы «2015-2025 елларга Биектау муниципаль районының коррупциягә каршы көрәш муниципаль программасы»н раслау турында» карарына (12.05.2016 №765, 26.05.2016 №849, 14.09.2018 №2001, 02.02.2019 № 405, 12.10.2021 №843, 20.07.2022 №721 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: карарның исеме түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

- «2015-2026 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында»;

2. «2015-2026 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын яңа редакциядә кушымта нигезендә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы сайтында (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга..

Д.Ф.Шәйдулли

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 14 февралендәге 189
Номерлы карарына кушымта

**«2015-2026 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы**

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2015-2026 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасы (далее - Программа) |
| Программаның заказчысы | Биектау муниципального районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты,<br>Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе |
| Программаның максатлары | Коррупциянең сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау), коррупциягә каршы тору шартларын тудыру, җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп тормау мөнәсәбәтен формалаштыру |
| Программның бурычлары | 1. Коррупциягә каршы көрәш, шул исәптән хокукый һәм оештыру инструментларын һәм механизмнарын камилләштерү.<br>2. Норматив муниципаль хокукый актларда һәм норматив муниципаль хокукый актлар проектларында коррупциягә каршы экспертиза уздыру, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү юлы белән коррупциоген факторларны ачыклау һәм бетерү.<br>3. Мониторинг тикшеренүләре уздыру юлы белән коррупция торышын бәяләү.<br>4. Коррупциягә каршы белем бирүне һәм коррупциягә каршы пропаганданы активлаштыру, кадрлар, мәгълүмати һәм гражданнар җәмгыятенең башка ресурсларын коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү.<br>5. Халык өчен муниципаль органнар эшчәнлеге ачыклыгын, һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү, аларның граждан җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру.<br>6. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү.<br>7. Эшмәкәрлеккә (бизнес-структурага) административ басымның эзлекле киметү.<br>8. Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру.<br>9. Көнкүреш коррупциясен минимальләштерү чараларын көчәйтү.<br>10. Муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы торышын стимуллаштыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм | I этап: 2015-2023 еллар; |

| | |
|---|---|
| этаплары | II этап 2024 – 2026 еллар. |
| Программаны гамәлгә ашыруның бөтен чорына финанс белән тәэмин итү күләмнәре (чыганак һәм күләмнәр) | Биектау муниципаль районы бюджеты, Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне агымдагы финанслау.<br>I этап: 2015-2023 еллар-1 130 000 сум;<br>II этап: 2024 – 2026 елла - 330 000 сум.<br>2024-110 000 сум<br>2025-110 000 сум<br>2026-110 000 сум |
| Программаның максатларын һәм бурычларын (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча 2026 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:<br>- Биектау муниципаль районының кадрлар сәясәтенә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм керткән җирле үзидарә органнары өлеше 100 процентка җитәчәк;<br>- аларның проектларын эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән муниципаль норматив хокукый актлар өлеше 100 процентка җитәчәк;<br>-социологик сорашып белешүләр оештыруга муниципаль бирем 100 процентка үтәләчәк;<br>- квалификация күтәрүне узган муниципаль хезмәткәрләр өлеше ел саен кимендә 33 процент тәшкил итәчәк; коррупциягә каршы көрәш эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләре буенча методик материаллар белән җирле үзидарә органнарының 100 проценты тәэмин ителәчәк;<br>-коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль учреждениеләр өлеше кимендә 50 процент тәшкил итәчәк; - гражданнарның муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>- тору урыны буенча "бер тәрәзә" принцибы буенча муниципаль хезмәтләр алуга мөмкинлеге булган гражданнар өлеше, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>-«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча үзенең рәсми сайтларын мәгълүмат белән тулыландыруны һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайты бүлекләрен тулыландыруны тәэмин итүче Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары өлеше кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>- Биектау муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны оештыру һәм уздыру өлкәсендәге эшчәнлекнең үтә күренмәлелеген тәэмин иткән җирле үзидарә органнары өлеше кимендә 100 процент тәшкил итәчәк;<br>-коррупция ситуациясенә эләккән эшкуарлар өлеше (Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты уздыра торган социологик тикшеренүләре мәгълүматлары буенча) 13,7 проценттан артмаячак;<br>- Программада каралган контроль тикшерүләрне гамәлгә ашыру тулылыгы кимендә 100 процент тәшкил итәчәк;<br>-үз проблемаларын хәл итүгә вакыты яисә мөмкинлекләре булмау сәбәпле (Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты уздыра торган социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча) коррупция килешүенә керүче Биектау муниципаль районында яшәүчеләрнең өлеше 21,5 проценттан артмаячак;<br>-мәгариф оешмаларында законсыз рәвештә акча җыю очраклары турында белешмәлек алган мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның ата-аналары өлеше кимендә 100 процент тәшкил итәчәк;<br>- муниципаль хезмәтнең абруен арттыруга юнәлтелгән чаралар ел саен үткәреләчәк. |
| Россия Федерациясе үсешенең милли | - Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 |

| | |
|---|---|
| максатлары, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын Социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Стратегия-2030) белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенең максатлары, Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы белән элемтә | июлендәге 400 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе милли иминлеге стратегиясе;<br>- Стратегия-2030;<br>- Россия Федерациясе Президентының «2021 - 2024 елларга коррупциягә каршы көрәшнең милли планы турында» 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Указы белән расланган 2021 - 2024 елларга коррупциягә каршы көрәш милли планы;<br>- «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы;<br>- «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы. |

## I. ПРОГРАММАНЫҢ ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

Коррупция дәүләтнең һәм җәмгыятьнең социаль-икътисадый үсешенә тискәре йогынты ясый, көндәшлеккә сәләтле икътисад формалаштыруда киртә булып тора, халыкның тормыш дәрәҗәсен үстерүгә, җитлеккән граждан җәмгыяте аякка басуга каршылык каршылык тудыра. Шуңа бәйле рәвештә соңгы еллар Татарстан Республикасында һәм шулай ук Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча, барлык дәрәҗәләрдә закон чыгару һәм хокук куллану эшен камилләштерү буенча чаралар активлашу белән харатерлана.

Әлеге Программа, «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын исәпкә алып, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде.

Программа федераль һәм республика дәрәҗәсендә гамәлгә ашырыла торган коррупциягә каршы көрәш чаралары системасы белән концептуаль яктан бәйле һәм муниципаль дәрәҗәдә коррупциягә каршы эшне оештыруда программа-максатчан методны кулланунының алшартларын тудыра.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕ, МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ ТӨП БУРЫЧЛАРЫ. ПРОГРАММАНЫҢ КӨТЕЛГӘН АХЫРГЫ НӘТИҖӘЛӘРЕН ТАСВИРЛАУ, АНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОКЛАРЫ ҺӘМ ЭТАПЛАРЫ

ПРограмманың өстенлекләре «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә (алга таба - Стратегия-2030), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе милли иминлеге стратегиясе (алга таба - Россия Федерациясе милли иминлеге стратегиясе), Россия Федерациясе Президентының «2021 - 2024 елларга коррупциягә каршы тору милли планы турында» 2021 елның 16 августындагы 478 номерлы Указы белән расланган 2021 - 2024 елларга коррупциягә каршы тору милли планына туры килә.

Программа коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерүгә (коррупцияне профилактикалау), коррупциягә каршы тору шартларын тудыруга, җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп тормау булдыруга юнәлтелгән.

Программа максатлары булып түбәндәгеләр тора:

1 максат: коррупциягә каршы торуның оештыру һәм хокукый, шул исәптән кадрлар сәясәтендә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм, чаралары күрелгән җирле үзидарә органнарының 100 процент колачлавын тәэмин итү белән характерлана торган коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау).

2 максат: коррупциягә каршы тору шартларын тудыру, ул түбәндәге күрсәткечләргә ирешү белән характерлана:

- коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән закон чыгару һәм башка норматив хокукый актларның, шулай ук норматив хокукый актлар проектларының өлешен арттыру;

- коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль хезмәткәрләрнең өлешен арттыру.

3 максат: җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп булмаслык мөнәсәбәт формалаштыру, ул коррупция ситуациясенә эләккән гражданнар өлешенең артуы белән характерлана, алар коррупция килешүенә керергә баш тарткан.

«Коррупция сәбәпләрен ачыклау һәм бетерү (коррупцияне профилактикалау)» максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

- коррупциягә каршы көрәш, шул исәптән хокукый һәм оештыру инструментларын һәм механизмнарын камилләштерү;
- эшкуарлыкка (бизнес-структура) административ басымны эзлекле киметү;
- җирле үзидарә органнарының хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- көнкүреш коррупциясен минимальләштерү чараларын көчәйтү.

«Коррупциягә каршы шартлар тудыру» максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

-норматив муниципаль хокукый актларда һәм норматив муниципаль хокукый актлар проектларында коррупциягә каршы экспертиза уздыру юлы белән коррупциоген факторларны ачыклау һәм бетерү;

-коррупциягә каршы укытуны оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганданы гамәлгә ашыру, кадрлар, матди, мәгълүмат һәм гражданлык җәмгыятенең башка ресурсларын коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү;

- халык өчен ачык хакимият органнары эшчәнлегендә ачыклыкны, халыкның файдалана алуын тәэмин итү, аларның гражданнар җәмгыяте белән элемтәләрен ныгыту, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру;

- муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү.

«Җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп булмаслык мөнәсәбәт формалаштыру» максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

-Биектау муниципаль районында коррупция торышын бәяләүне уздыру;

- норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыруга эксперт җәмәгатьчелеген җәлеп итү;

- гражданнарда коррупциягә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру.

**<u>Программаны гамәлгә ашыру йомгаклары буенча 2026 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:</u>**

- Биектау муниципаль районының кадрлар сәясәтенә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм керткән җирле үзидарә органнары өлеше 100 процентка җитәчәк;
- аларның проектларын эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән муниципаль норматив хокукый актлар өлеше 100 процентка җитәчәк;
-социологик сорашып белешүләр оештыруга муниципаль бирем 100 процентка үтәләчәк;
- квалификация күтәрүне узган муниципаль хезмәткәрләр өлеше ел саен кимендә 33 процент тәшкил итәчәк;
- коррупциягә каршы көрәш эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләре буенча методик материаллар белән җирле үзидарә органнарының 100 проценты тәэмин ителәчәк;
-коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль учреждениеләр өлеше кимендә 50 процент тәшкил итәчәк;
- гражданнарның муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;
- тору урыны буенча "бер тәрәзә" принцибы буенча муниципаль хезмәтләр алуга мөмкинлеге булган гражданнар өлеше, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;

- Биектау муниципаль районының рәсми сайтын мәгълүмат белән тулыландыруны тәэмин итүче Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары өлеше кимендә 100 процент тәшкил итәчәк;

- Биектау муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны оештыру һәм уздыру өлкәсендәге эшчәнлекнең үтә күренмәлелеген тәэмин иткән җирле үзидарә органнары өлеше кимендә 100 процент тәшкил итәчәк;

- коррупция ситуациясенә эләккән эшкуарлар өлеше (Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты уздыра торган социологик тикшеренүләре мәгълүматлары буенча) 13,7 проценттан артмаячак;

- Программада каралган контроль тикшерүләрне гамәлгә ашыру тулылыгы кимендә 100 процент тәшкил итәчәк;

-үз проблемаларын хәл итүгә вакыты яисә мөмкинлекләре булмау сәбәпле (Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитеты уздыра торган социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча) коррупция килешүенә керүче Биектау муниципаль районында яшәүчеләрнең өлеше 21,5 проценттан артмаячак;

-мәгариф оешмаларында законсыз рәвештә акча җыю очраклары турында белешмәлек алган мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның ата-аналары өлеше кимендә 100 процент тәшкил итәчәк;

- муниципаль хезмәтнең абруен арттыруга юнәлтелгән чаралар ел саен үткәреләчәк.

Программаны гамәлгә ашыру сроклары: 2015 - 2026 годы.

I этап: 2015 – 2023 еллар;

II этап: 2024 – 2026 еллар.

Программаның төп максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары, шулай ук Программада каралган чараларны финанслау күләмнәре Программага кушымтада бирелгән.

## III. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕ ТАСВИРЛАУ

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, Биектау муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Моннан тыш, программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчаларны файдалану күздә тотыла.

## IV. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программаның үтәлешен планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияне һәм гомуми контрольне Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе гамәлгә ашыра, ул ел саен Программа чараларының максатчан күрсәткечләрен һәм аларга чыгымнарны, Программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручылар составын аныклый, Биектау муниципаль районының чараларны үтәү өчен җаваплы җирле үзидарә органнарыннан, учреждениеләреннән һәм оешмалардан, Программаның үтәлеше турында белешмәләр соратып ала.

Тиешле чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы Программаларны үтәүчеләр Биектау муниципаль районы Башлыгына - Биектау

муниципаль районында коррупциягә каршы көрәшне координацияләү буенча комиссия рәисенә квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 1 числосына кадәр чараларны башкару һәм чараларны башкаручыларга бүлеп бирелә торган акчаларны тоту турында, арта барган нәтиҗә белән һәм тулаем хисап елында башкарыла торган чаралартурында мәгълүмат бирәләр.

Еллык хисап Биектау муниципаль районы башлыгына - Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе рәисенә - бирелә һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләр;
- билгеләнгән вакытта башкарылган һәм үтәлмәгән (сәбәпләрен күрсәтеп) чаралар исемлеге;
- Программаны гамәлгә ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлау;
- чараларны үтәүгә акчалардан файдалану турындагы күрсәткечләр;
- башка мәгълүматны.

Программага үзгәрешләр кертү Программаның чараларын җаваплы башкаручы инициативасы буенча һәм аның белән килештереп йә Биектау муниципаль районы башлыгы - Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе рәисе йөкләмәләрен үтәү йөзеннән, билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## V. ПРОГРАММАНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ

Программаның гомуми нәтиҗәлелеге 2026 елга планлаштырылган билгеләнгән максатчан параметрларга ирешү, каралган чараларны билгеләнгән срокларда гамәлгә ашыру дәрәҗәсе буенча бәяләнә. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен социологик тикшеренүләр нәтиҗәләре, шулай ук агымдагы хисап материаллары файдаланыла. Программа чараларын гамәлгә ашыру 2026 елга түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә муниципаль идарәнең нәтиҗәлелеген арттырырга;
- Биектау муниципаль районында җирле үзидарә органнарының коррупциягә каршы эшчәнлегендә җәмәгатьчелек ролен күтәрү;
- Җәмгыятьтә коррупциягә каршы түзеп булмаслык мөнәсәбәт формалаштыру.

Программаның социаль нәтиҗәсе гражданнарның үз конституциячел хокукларын һәм ирекләрен тулырак гамәлгә ашыруы белән бәяләнә.

Программаның үзенчәлеген исәпкә алып, туры икътисадый нәтиҗәне билгеләү мөмкин түгел, чөнки программа чаралары гади статистик үлчәүләргә бирелми һәм хаклар бәяләвендә чагыла алмый. Шул ук вакытта Программа чараларын гамәлгә ашыруның кыек икътисадый нәтиҗәсе Биектау муниципаль районының җәлеп итүчән имиджын формалаштыру, шул исәптән инвестиция җәлеп итүчәнлеге, эшкуарлык активлыгын күтәрү, Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупция чагылышларына бәйле бюджет югалтуларын киметү нәтиҗәсендә күзәтелергә мөмкин.

Программада эшчәнлекнең нәтиҗәләрен характерлаучы индикаторлар һәм күрсәткечләр системасы кулланыла. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү аны гамәлгә ашыруның бөтен чорында аны 2026 елга кадәр Программаны үтәү нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары буенча аңа кушымтада китерелгән күрсәткечләргә ирешүне исәпкә алып уздырыла.

«2015-2026 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына кушымта
(Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма
комитетының 2024 елның «___»__ ___ ___
номерлы карары редакциясендә)

**1. 2015 - 2026 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру коррупциягә каршы муниципаль программаның бурычлары, чаралары һәм индикаторлары**

| № т/б | Чараның исеме | Җаваплы башкаручылар | Гамәлгә ашыру чоры | Индикатор исеме | Индикаторның үлчәү берәмлеге | Индикаторның база кыйммәте | Индикаторның еллар буенча план кыйммәтләре | | | | Еллар буенча финанслау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | кыйммәте | ел | 2024 | 2025 | 2026 | 2024 | 2025 | 2026 |
| 1 | 2 | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | | | |
| | 1 бурыч. Биектау муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш инструментларын һәм механизмнарын, шул исәптән хокукый һәм оештыру механизмнарын камилләштерү | | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | Биектау районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларын эшләү һәм Биектау районы җирле үзидарә органнарының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларына | БМР Советы (килешү буенча), БМР БК, БМР ОМС (килешү буенча) | 2024-2026 еллар. | Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә Биектау районы җирле үзидарә органнарының федераль һәм республика законнарына | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә федераль, республика законнарын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасында гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану тәҗрибәсен гомумиләштерү нигезендә үзгәрешләр кертү (кирәк булганда гамәлгә ашырыла). | | | туры китерелгән муниципаль норматив хокукый актлары өлеше. | | | | | | | | | |
| 1.2. | «Федераль дәүләт хезмәте Вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 | БМР ОМС (килешү буенча) | 2024-2026 еллар. | Коррупциягә каршы тору буенча кабул ителгән оештыру һәм хокукый чаралар, шул исәптән кадрлар сәясәтендә эчке контроль һәм коррупциягә каршы көрәш механизмы. | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | номерлы Указы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәвен тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча Биектау районы җирле үзидарә органнары | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бүлекчәләренең (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәтләренең вазыйфаи затларының) нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү. | | | | | | | | | | | | |
| 1.3. | Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан функцияләрен гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган коррупция куркынычын бәяләүне үткәрү һәм, аларны биләү коррупция куркынычларына бәйләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә төгәлләштерүләр кертү (кирәк булганда) үткәрү. | БМР ОМС (килешү буенча) | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |
| 1.4. | Биектау районы коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе эшләренең еллык планнарын раслау һәм үтәү. | БМР ОМС (килешү буенча) | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.5. | Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең шәхси эшләренә анализ ясау һәм мондый хезмәткә кергәндә тапшырыла торган аларның туганнары һәм якыннары турында анкеталардагы белешмәләрне (абыйларының һәм сеңелләренең хатыннары, ирләре, һәм ирләре белән хатыннарының туганнары сеңелләре турында), мөмкин булган мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау максатларында актуальләштерү, | кадрлар хезмәт енең җаваплы хезмәткәре | 2024-2026 еллар. | Биектау районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре тарафыннан коррупциягә каршы көрәш өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларның бер елга планлаштырыл ганнарның гомуми санынннан өлеше. | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | | | |
| 1.6. | Биектау муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан муниципаль хезмәт турындагы законнарда каралган чикләүләр һәм тыюларның үтәлешенә, шул исәптән эшкуарлык | кадрлар хезмәт енең җаваплы хезмәткәре | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | эшчәнлегендә катнашу предметына, «Юридик затларның бердәм дәүләт реестры» һәм «Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестры» федераль салым хезмәтенең белешмәләр базасыннан файдаланып, башка мәгълүмат системаларыннан (елына кимендә бер мәртәбә) тикшерү үткәрү. | | | | | | | | | | | | |
| 1.7. | Биектау муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның коммерция оешмалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар идарәсендә катнашуларына мониторинг ясау. | кадрлар хезмәт енең җаваплы хезмәткәре | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |
| 1.8. | «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы | кадрлар хезмәт енең җаваплы хезмәткәре, Коррупция | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | нигезләмәләрендә каралган чараларны күрү бурычын үтәүне тәэмин итү максатларында коррупцияне кисәтү, шул исәптән оешмалар тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын ачыклау, булдырмау һәм җайга салу буенча Биектау районы җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмалар белән эш алып бару. | гә каршы көрәш мәсьәләләре буенча район Башлыгы ярдәмчесе | | | | | | | | | | | |
| 1.9. | Осуществление контроля за применением предусмотренных законодательством мер юридической ответственности в каждом случае несоблюдения запретов, ограничений и требований, установленных в целях противодействия коррупции. | кадрлар хезмәт енең җаваплы хезмәткәре, Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча район Башлыгы ярдәмчесе | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |
| 1.10. | Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар | кадрлар хезмәт енең җаваплы | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмауга һәм җайга салуга кагылышлы коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары таләпләренең үтәлүен, шул исәптән алар үтәлмәгән очракта, мондый затларны җаваплылыкка җәлеп итүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру. | хезмәткәре, Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча район Башлыгы ярдәмчесе | | | | | | | | | | | |
| | 2 бурыч. Биектау районы җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларында коррупциягә каршы экспертиза уздыру юлы белән коррупциоген факторларны ачыклау һәм бетерү, Биектау районы җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү. | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. | Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен шартлар тәэмин итү һәм күрсәтелгән экспертизаны уздыру нәтиҗәләрен гомумиләштерү. | БМР Советының Юридик бүлеге (килешү буенча), БМР БК, ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләр, ОМС | 2024-2026 гг. | Биектау районының җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2. | Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләнгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларын норматив хокукый актлар проектларын әзерләү һәм аларны җәмәгать фикер алышуы нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыру өчен төзелгән рәсми сайтта урнаштыру [http://tatarstan.ru/regulation](http://tatarstan.ru/regulation). | (килешү буенча), ФБП (килешү буенча), ПИЗО (килешү буенча), КСП (килешү буенча) | 2024-2026 еллар. | өлеше. | | | | | | | | | |
| | 3 бурыч. Биектау муниципаль районында коррупция торышын бәяләү. | | | | | | | | | | | | |
| 3.1. | Максатчан төркемнәр арасында коррупциоген факторларны һәм гамәлгә ашырыла торган коррупциягә каршы чараларны тармак тикшеренүләре уздыру һәм күрсәтелгән тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен бастырып чыгару. | БМР Советы (килешү буенча), БМР БК, БМР ОМС (килешү буенча) | 2024-2026 еллар. | Үткәрелгән тикшеренүләр саны. | шартлы берәмлек | 1 | 2023 | 1 | 1 | 1 | | | |
| | 4 бурыч. Коррупциягә каршы укуны оештыру һәм коррупциягә каршы пропаганда, кадрлар, матди, мәгълүмат һәм граждан җәмгыятенең башка ресурсларын коррупциягә каршы көрәшкә җәлеп итү. | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1. | Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аның карамагындагы оешмаларда коррупциягә карата тискәре мөнәсәбәт булдыру, шул исәптән коррупциягә каршы көрәштә катнашучы иҗтимагый советларны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм граждан җәмгыятенең башка институтларын җәлеп итеп, коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар күрү, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәү буенча эш башкару. | кадрлар хезмәт енең җаваплы хезмәткәре, Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча район Башлыгы ярдәмчесе | 2024-2026 еллар. | Коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән Биектау районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өлеше. | процент | 50 | 2023 | 100 | 100 | 100 | | | |
| 4.2. | Район иҗтимагый советы утырышларында коррупциягә каршы | Иҗтимагый совет рәисе, кадрлар | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | көрәш программаларын гамәлгә ашыру турында хисапларны карау. | хезмәт енең җаваплы хезмәткәре, Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча район Башлыгы ярдәмчесе | | | | | | | | | | | |
| 4.3. | Коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналарны белем бирү программаларына кертеп, Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен квалификация күтәрү программалары буенча укытуны оештыру. | кадрлар хезмәт енең җаваплы хезмәткәре, ОМС (килешү буенча) | 2024-2026 еллар. | Коррупциягә каршы тематика буенча дисциплиналар кертелгән программалар буенча квалификация күтәрү узган Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре өлеше | процент | 33 | 2023 | 33 | 33 | 33 | | | |
| 4.4. | «Минем илемнең киләчәге - минем кулымда!» сочинениеләр конкурсы, | Башкармак омитетның «Мәгариф бүлеге» МУ, | | | | | | | | | 50,0 | 50,0 | 50,0 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Коррупциягә - «Юк»!» темасына туган телдә милли мәктәпләр укучыларының иҗади эшләре һәм «Намуслы яшәргә кирәк!» балалар рәсемнәре, «Закон сагында, коррупциягә каршы» һөнәри белем бирү оешмалары студентлары арасында иҗади эшләр республика конкурсын үткәрү | ОДМС, «Мәдәният бүлеге» МКУ | | | | | | | | | | | |
| 4.5. | Ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә коррупциягә каршы көрәш буенча ОМСта методик мәгълүмат материалларын әзерләү, тарату һәм актуальләштерү | ведомство учреждениеләренәия ОМС, ОДМС, «Мәдәният бүлеге» МКУ | | | | | | | | | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| 4.6. | ОМС һәм муниципаль учреждениеләр өчен коррупциягә каршы темага социаль баннерлар әзерләү | ведомство учреждениеләренәия ОМС, ОДМС, «Мәдәният бүлеге» МКУ | | | | | | | | | 50,0 | 50,0 | 50,0 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 бурыч. Биектау районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачык булуын, гражданнарның файдалана алуын тәэмин итү, граждан җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлек итү, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыру. | | | | | | | | | | | | | |
| 5.1. | Биектау районының җирле үзидарә органнарында ышаныч телефоннары, кайнар линияләр, интернет-кабул итү каналлары, аларга мәгълүм коррупция фактлары, аларны башкаруга ярдәм итүче сәбәпләр һәм шартлар турында хәбәр итәргә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүмат каналлары эшчәнлеген тәэмин итү. | ОМС (килешү буенча) | 2024-2026 еллар. | Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгын, гражданнарның файдалана алуын тәэмин итүгә, гражданнар җәмгыяте белән үзара хезмәттәшлеккә, җәмәгатьчелекнең коррупциягә каршы активлыгын стимуллаштыруга юнәлдерелгәнуздырылган чараларның, бер елга планлаштырылган гомуми саныннан өлеше. | процент | 100 | 2023 | 100 | 100 | 100 | | | |
| 5.2. | Массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылган һәм гражданнар һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрендә булган, квартал саен гомумиләштерелгән һәм аның нәтиҗәләрен коррупциягә каршы көрәш комиссияләре утырышларында, районның коррупциягә каршы | кадрлар хезмәтенең җаваплы хезмәткәре, Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буен ча район Башлыгы ярдәмчесе | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясендә тикшереп торылган Биектау муниципаль районы вазыйфаи затлары эшчәнлегендә коррупциячел күренешләр турында мәгълүмат мониторингы үткәрү. | | | | | | | | | | | | |
| 5.3. | Мәгълүмати стендларын, Биектау муниципаль районының рәсми сайтының “Коррупциягә каршы тору” бүлеген һәм коррупциягә каршы тору турында мәгълүмат бирүнең башка рәвешләрен формалаштыру һәм актуальләштерү. | кадрлар хезмәт енең җаваплы хезмәткәре, Корруп циягә каршы көрәш мәсьәләләр е буен ча район Башлыгы ярдәмчесе | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |
| 5.4. | Тормыш эшчәнлегенең социаль-икътисадый тармакларында коррупция чагылышлары турында гражданнар мөрәҗәгатьләренә мониторинг үткәрү. | Корруп циягә каршы көрәш мәсьәләләр е буен ча район Башлыгы ярдәмчесе | 2024-2026 еллар. | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 бурыч. Биектау муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашырганда ачыклыкны, намуслы конкуренцияне һәм объективлыкны тәэмин итү. | | | | | | | | | | | | |
| 6.1. | униципаль ихтыяҗлар товарларын (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алуны гамәлгә ашырганда коррупция дәрәҗәсен киметүгә ярдәм итә торган чараларны гамәлгә ашыру, шул исәптән гамәлгә ашырыла торган сатып алуларның ачыклыгын һәм алардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү чараларын үткәрү, шулай ук сатып алуларда катнашучыларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру. | икътисадны һәм сатуны кураторлаучы БМР РИК урынбасары, БМР РБК икътисад бүлеге, ОМС (килешү буенча) | 2024-2026 еллар. | Аларны үткәр ү барышында контроль органнары тарафыннан сатып алу объектын тасвирлау кагыйдәләрен һәм контрактның башлангыч макси маль бәясен формалаштыру кагыйдәләр ен бозган өчен Биектау муниципаль районы вазыйфаи затын административ җаваплы лыкка тарту турында карар чыгарылган сатып алулар өлеше[1]. | шартлы берәмлек | 0 | 2023 | 30 | 30 | 30 | | | |

Кулланылган кыскартылмалар исемлеге:
- Район - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы;

[1]Күрсәткечнең ≤ 30 тамгалы кыйммәте.

- БМР Советы - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы;
- БМР РИК –Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;
- БМР БК - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты;
- ОМС - җирле үзидарә органнары;
- ФБП – Финанс - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының бюджет палатасы;
- ПИЗО – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы;
- КСП –Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Контроль - хисап палатасы.